


**Бөек татар мәгърифәтчесе, язучы, фольклорчы, тел галиме Каюм Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан башкалабызда чаралар шактый үткәрелә. 24 февраль көнне «Апуш» татар балалар театр студиясе «Чулпан» мәдәният үзәгендә мәшһүр язучының «Әбүгалисина» мюзиклын күрсәтте. Балаларны һәм яшүсмерләрне театр аркылы татар телен популярлаштыруга, татар әдәбиятын, иҗатын, сәнгатен үстерүгә юнәлдерелгән әлеге чарадан 79 нчы экология-технология лицее укучылары да читтә калмады, спектакльне тамаша кылып кайтты алар. Зирәк сүзнең кодрәте, белемгә мәхәббәт һәм гыйлемгә омтылу турындагы бу тарих укучылар күңелендә озак сакланыр!**








ЛИЦЕЙ №79